Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районының
Янил авыл җирлеге Советы

КАРАР

22 март, 2024 ел № 13

Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахит авылы торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахит торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 24 ноябрендәге 2 номерлы Вахит авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Янил авыл җирлеге Уставы нигезендә Янил авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елның 6 апреленә 14 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахит торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 24 ноябрендәге 2 номерлы Вахит авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Вахит авылы, Клуб урамы, 12 адресында урнашкан Вахит авыл мәдәният йорты бинасында уздырырга.

2. 2024 елның 6 апреленә 16 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахит торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 24 ноябрендәге 2 номерлы Вахит авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Вахит авылы, Клуб урамы, 12 адресында урнашкан Вахит авыл мәдәният йорты бинасында уздырырга.

3. 2024 елның 6 апреленә 18 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахит торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 24 ноябрендәге 2 номерлы Вахит авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Вахит авылы, Клуб урамы, 12 адресында урнашкан Вахит авыл мәдәният йорты бинасында уздырырга.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахит авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 24 ноябрендәге 2 номерлы карарына түбәндәге мәсьәлә буенча үзгәрешләр кертүгә ризамы: «Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Янил авыл җирлеге Вахит авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия

Федерациясе Кораллы Көчләренә срокы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Коралллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 6550 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Вахит авылында юлларга вак таш җәю һәм ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

2) Вахит авылында һәйкәлне төзү, ремонтлау һәм аның тирәсендәге территорияне төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

3) Вахит авылында урам юл челтәрен карап тоту, юл билгеләре сатып алу, урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

4) Вахит авылына энергия саклаучы лампалар, светодиодлы яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, ремонтлау, Вахит авылында урам яктыртуны карап тоту, ясау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

5) Вахит авылы зиратлары территориясен, янәшәдәге территорияләрне төзекләндерү һәм карап тоту, зиратларның коймаларын ремонтлау һәм карап тоту, җирләү йортларын ремонтлау, зиратка илтә торган җәяүлеләр күперен ремонтлау, инвентарь сатып алу, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

6) парклар, яр буйлары, спорт мәйданчыклары һәм халыкның башка күпләп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау, аларга якын территорияне төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

7) җәяүлеләр кичүен һәм тротуарны ремонтлау, төзү һәм карап тоту, тротуар өчен бордюрлар сатып алу, урнаштыру һәм алар тирәсендәге территорияне төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

8) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү, янгын гидрантларын, янгын сүндерү савытлары һәм кирәкле җиһазлар, инвентарь сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын төзү; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

9) торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне карап тоту, ремонтлау һәм оештыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

10) массакүләм ял итү урыннарын чүп-чар урналары белән җиһазландыру;

11) Чишмәләрне, чишмә йортларын (будкаларын) һәм аларга якын территорияләрне урнаштыру, төзү, ремонтлау һәм тоту, чишмәгә керү юлларына вак таш салу , асфальт җәю, парковкалар, яктырту урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру

түләү күләмен 6550 сумнан 3454 сумга үзгәртү һәм 2023 елның 24 ноябрендәге 2 номерлы карарында күрсәтелгән эш төрләрен үзгәртү өлешендә түбәндәге эшләр белән:

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Вахит авылына энергия саклаучы лампалар, светодиодлы яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, ремонтлау; проект-смета документларын эшләү);

- урам яктыртуны ясау Вахит авылында урам яктыртуны карап тоту, ясау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру)

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны,

транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары төзү һәм ремонтлау (торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне карап тоту, ремонтлау һәм оештыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (чишмәләрне, чишмә йортларын (будкаларын) һәм аларга якын территорияләрне урнаштыру, төзү, ремонтлау һәм тоту, чишмәгә керү юлларына вак таш салу , асфальт җәю, парковкалар, яктырту урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү, янгын гидрантларын, янгын сүндерү савытлары һәм кирәкле җиһазлар, инвентарь сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- һәйкәлләрне төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаганнары) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (Вахит авылында һәйкәлне төзү, ремонтлау һәм аның тирәсендәге территорияне төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Вахит авылындагы юлларга вак таш җәю һәм ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру); (Вахит авылында урам юл челтәрен карап тоту; юл билгеләре сатып алу, урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- тротуарлар ясау, ремонтлау (җәяүлеләр кичүен һәм тротуарны ремонтлау, төзү һәм карап тоту, тротуар өчен бордюрлар сатып алу, урнаштыру һәм алар тирәсендәге территорияне төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (парклар, яр буйлары, спорт мәйданчыклары һәм халыкның башка күпләп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау, аларга якын территорияне төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү (Вахит авылы зиратлары территориясен, янәшәдәге территорияләрне төзекләндерү һәм карап тоту, зиратларның коймаларын ремонтлау һәм карап тоту, җирләү йортларын ремонтлау, зиратка илтә торган җәяүлеләр күперен ремонтлау, инвентарь сатып алу, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- каты көнкүреш калдыкларын туплау мәйданчыкларын төзү, каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү (массакүләм ял итү урыннарын чүп-чар урналары белән җиһазлау).

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Янил авыл җирлеге башлыгы: И.Х. Корбанов